| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№139**

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 25 декабрендәге 828 номерлы карары белән расланган 2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль программаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
10.02.2020 елның 139 номерлы карарын
кушымта

**«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ҺӘМ ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ҺӘМ ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ
ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Кукмара муниципаль районында 2018 – 2020 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау муниципаль Программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;<br>«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы законы |
| Программаның муниципаль заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Муниципаль программаның төп эшләүчеләре | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны башкаручылар | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Хезмәтне саклау буенча Координация советы;<br>Кукмара муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары (килешү буенча) |
| Программаның максатлары | Оешма хезмәткәрләренең җитештерү травматизмын һәм һөнәри хәвеф-хәтәрләрен киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |
| Программаның бурычлары | Программаның төп бурычлары:<br>- заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү;<br>- хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Финанслау күләме, чыганаклары | Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Мөһим максатчан индикаторлар һәм программаның күрсәткечләре | Программа максатларына һәм бурычларына ирешү индикаторлары (күрсәткечләре):<br>- хезмәтне саклау буенча укулар узган җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм белгечләренең саны – 30 кеше;<br>- производствода имгәнү һәм бәхетсезлек очраклары дәрәҗәсен 15% ка кимүе |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре, нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1. Социаль эффект:<br>- Җитештерү травматизмы һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен кимү;<br>- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- начар хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрнең саны кимү.<br>2. Икътисади нәтиҗә:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан, җитештерү-билгеләнгән авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү; |

| | |
|---|---|
| | - производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;<br>- зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;<br>- эш вакытын югалтуларны киметү хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.<br>3. Экологик:<br>- технологик процессларны, җайланмаларны камилләштерү нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә зарарлы матдәләр чыгарылмау |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты һәр ел нәтиҗәләре буенча программаны тормышка ашыруны контрольдә тота. Билгеләнгән тәртиптә, килеп туган социаль-икътисадый ситуацияне исәпкә алып, Программа чараларын төгәлләштерү буенча тәкъдимнәр кертә |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программаны Кукмара муниципаль районында муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә эшләү һәм гамәлгә ашыру кирәклеген билгеләүче мөһим фактор булып, бу проблеманың районның эшкә сәләтле халкының тормыш сыйфатын күтәрү һәм сәламәтлеген саклау өлешендә социаль әһәмияте зур булуы тора.

Программа яңа икътисадый һәм хезмәт мөнәсәбәтләренә туры килә торган хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасын алга таба камилләштерүгә, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган хезмәт шартларын тәэмин итүгә, дәүләт гарантияләре һәм хезмәтне саклау һәм яклауга, җитештерүдәге имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтү һәм профилактикалауга юнәлдерелгән

Хәзерге икътисади шартларда җәмгыятьнең социаль-икътисади иминлегенә эш урыннарында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары булдыру зур йогынты ясый.

Кукмара муниципаль районында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге хәл, тулаем алганда, Татарстан Республикасы белән чагыштырганда, яхшырак. Районда соңгы елларда үлем белән дә, производствода авыр җәрәхәтләр алган хезмәткәрләрнең дә производствода имгәнү очраклары кимүнең уңай тенденциясе ныгыды.

Җитештерү травматизмы күрсәткечләре
2015 – 2017 елларда

1 нче таблица

Производствода һәлак булучылар саны (кеше)

| 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
|---|---|---|
| 1 | - | - |

2 нче таблица

Производствода зыян күрүчеләр саны (кеше)

| 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
|---|---|---|
| 4 | 0 | 2 |

Хезмәткәрләрнең иминлеге, аларның тормышы һәм сәламәтлеге хезмәтне саклау өчен бүлеп бирелгән суммадан турыдан-туры бәйле. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын финанслау Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә эш бирүченең бурычы булып тора.

Эш урыннарында һөнәри хәвеф-хәтәрләрне киметү максатларында хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрне максатчан укыту һәм һөнәри әзерләү мөһим. Районда бу мәсьәләгә аеруча зур игътибар бирелә, чөнки эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау өлкәсендә иң күп хокук бозулары хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне укыту һәм инструкцияләү мәсьәләләре белән бәйле.

Районда хезмәтне саклау буенча Координацион совет булдырылган һәм уңышлы эшләп килә. Хезмәтне саклау буенча Координация советы утырышларында хезмәт шартлары буенча укыту, эш урыннарын аттестацияләү, хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль Программа эшләү һәм кабул итү, производствода бәхетсезлек очракларына юл куйган предприятие җитәкчеләрен тыңлау һәм башка мәсьәләләр

карала.

Хезмәтне саклау өлкәсендә ирешкән уңай нәтиҗәләр дә бар, әмма вәзгыять шактый киеренке кала.

Производствода имгәнүнең сәбәпләрен анализлап, шуны әйтергә кирәк, соңгы елларда алар характерлары буенча үзгәрмәде. Төп сәбәпләре:

- хезмәт һәм җитештерү дисциплинасын бозу;
- куркынычсыз хезмәт шартларына өйрәтүдә җитешсезлекләр.

2. Программаның максатлары һәм бурычлары

2.1. Программаның максаты: Җитештерү травматизмы дәрәҗәсен киметү өчен, беренче чиратта, авыр һәм үлем белән тәмамланган очракларны киметү өчен, хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту, шәһәр оешмаларында һәм учреждениеләрендә һөнәри авыруларны профилактикалау, шулай ук шәһәрнең хезмәткә сәләтле халкының тотрыклы югары дәрәҗәдәге хезмәт активлыгын саклап калу өчен уңай шартлар булдыру да күздә тотыла.

2.2. Программаның бурычлары:

2.2.1. Заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү;

2.2.2. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау.

2.3. Программаның максатлары һәм бурычлары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары.

Куелган бурычларны хәл итүнең нәтиҗәлелеге түбәндәге индикаторлар дәрәҗәсенә ирешүдә чагыла:

2.3.1. Укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү.

Бурычны хәл итү нәтиҗәсе булып «Хезмәтне саклау буенча укуларын узган җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм белгечләренең саны – 30 кеше» индикаторына ирешү тора (3 нче таблица)

2.3.2. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау. Бурычны хәл итү нәтиҗәсе булып «Производствода имгәнүләр һәм бәхетсезлек очраклары дәрәҗәсен 15% ка киметү» индикаторына ирешү тора.

2.4. Программаны тормышка ашыру вакыты – 2018 – 2020 еллар.

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

3 нче таблица

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) (җирле бюджет) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Оешма хезмәткәрләренең җитештерү травматизмын һәм һөнәри хәвеф-хәтәрләрен киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту | - заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү; | хезмәтне саклау буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен укытуны оештыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар | хезмәтне саклау буенча укулар узган җитәкчеләр һәм белгечләр саны (кеше); | 15 | 15 | 15 | 0 | 0 | 10,0 |
| | - хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау | массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (оператив | | | производствода имгәнү һәм бәхетсезлек очракларының кимүе, % | 15 | 15 | 15 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгълүматны, хезмәтне саклау буенча норматив документларны бастырып чыгару һ. б.) | | | | | | | | | |

3. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

2018 – 2020 елларга Программаны финанслау күләме 10,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча: 2018 ел – 0 мең сум, 2019 ел – 0 мең сум, 2020 ел – 10,0 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы – Кукмара муниципаль районы бюджеты һәм бюджеттан тыш акчалар.

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

4. Программаны тормышка ашыру белән идарә итү һәм
аның үтәлешен контрольдә тоту

Программаны тормышка ашыру белән идарәне муниципаль заказчы – программаның координаторы – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Муниципаль заказчы – Программаның координаторы:

- максатчан индикаторларны, программа чараларын тормышка ашыру чыгымнарын, Программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны башкаручыларны әзерләү һәм аныклау эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыра;
- ел саен Программаны тормышка ашыру буенча эшләрнең барышы һәм билгеләнгән тәртиптә финанс чараларын кулланудың нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат җибәрә.

Программаны гамәлгә ашыру гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен продукция (хезмәт күрсәтүләр) сатып алу һәм җибәрүгә муниципаль контрактлар (шартнамәләр) нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре

Программа куелган максатларга ирешүне тәэмин итә торган оештыру, методик, санитар-гигиена, укыту-пропаганда, җитештерү һәм башка чараларның бердәм комплексы буларак формалаштырылган һәм тормышка ашырыла.

Программаны эшләгәндә программа чараларын гамәлгә ашырганда, социаль нәтиҗәгә ирешү өчен, аны тормышка ашыру чыгымнарын оптимальләштерүгә аерым игътибар бирелә.

Нәтиҗәләргә ирешүнең эффектлылыгы тормыш сыйфаты индикаторларының иң чик күрсәткечләренә ирешү белән билгеләнә:

- җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча укыту – 30 кешегә кадәр; 1000 эшчегә 18,25 кешегә кадәр;
- җитештерү травматизмы дәрәҗәсенең 15% ка кимүе.

Программаның социаль нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

- Җитештерү травматизмы һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киму;
- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;
- начар хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын кимүе;
- эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау проблемаларына игътибарын күбрәк җәлеп итү;
- шәһәр һәм район оешмаларында хезмәтне саклау буенча белгечләр санын арттыру.

Икътисади нәтиҗәлелек ул:

- производствода бәхетсезлек очракларыннан, җитештерү-билгеләнгән авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;
- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнарын киметү;
- зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;
- эш вакытын югалтуларны киметү һәм табыш күләмен арттыру хисабына хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;
- хезмәт шартларын яхшырту хисабына кадрларның алмашынып торуын киметү.

Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча чараларны гамәлгә ашыручы оешмалар шулай ук гамәлдәге закон таләпләрен бозган өчен штрафларны кыскарту хисабына икътисади нәтиҗә алалар.

Программаны тормышка ашыру халыкның, бигрәк тә эшкә яраклы яшьтә, үлем дәрәҗәсен киметү өчен уңай

шартлар тудыра.

Программа үтәлешенең экологик нәтиҗәсе – технологик процессларны камилләштерү нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә зарарлы матдәләр чыгарылмау, шулай ук искергән станокларны һәм җайланмаларны үз вакытында контрольдә тоту һәм алыштыру.

Программа чаралары исемлеге, аларны үтәү срокларын, күләмнәрен һәм финанслау чыганакларын күрсәтеп, Программаның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән.

2018 – 2020 елларга
Кукмара муниципаль районында
хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау
муниципаль Программасына 1 нче кушымта

## ХЕЗМӘТ ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ҺӘМ ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫ

| N N п / п | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Шул исәптән вакыты буенча (мең сум) | | | Үтәү вакыты (еллар) | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Хезмәтне саклау буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен укытуны оештыру | Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты, район предприятиеләре һәм оешмалары | 0,0 | 0,0 | 10,0 | 2018 – 2020 | җирле бюджет |
| 2 | Хезмәтне саклау буенча аерым җитәкчеләр һәм белгечләр өчен укулар үткәрүне оештыру | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары, Хезмәт, мәшгульлек, социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләре | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |
| 3 | Хезмәтне саклау буенча эшне иң яхшы оештыру буенча республика конкурсларында Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләренең катнашуын тәэмин итү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәдәният идарәсе, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Сәламәтлек саклау идарәсе | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 4 | Хезмәткәрләргә алдан (эшкә кергәндә) һәм медицина тикшерүләрен вакытында үткәрүне | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары, Хезмәт, | 100,00 | 100,00 | 100,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү | мәшгульлек, социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләре. | | | | | |
| 5 | Предприятиеләрдә зарарлы хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр өчен дәвалау-профилактика чараларын гамәлгә ашыру | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |
| 6 | Предприятиеләрдә начар хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләрне ел саен диспансерлаштыруны оештыру | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |
| 7 | Оешмаларда һәм предприятиеләрдә, барлык милек рәвешләрендәге учреждениеләрдә хезмәтне саклау буенча белгечләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү, алар өчен кирәкле шартлар тудыру | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 8 | Хезмәт шартлары буенча эш урыннары аттестациясен үткәрү, алга таба хезмәткәрләргә эш урыннарында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау, сәламәтлеккә зыян килү куркынычы, тиешле компенсацияләр һәм шәхси саклану чаралары турында мәгълүмат җиткерү | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |
| 9 | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә, оешмаларында хезмәтне саклау буенча кабинетлар төзү | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 10 | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә, учреждениеләрендә хезмәтне саклау буенча инженерны җиһазлар һәм техника җыелмасы булган аерым эш урыны белән тәэмин итү | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | «Хезмәтне саклау шартларын яхшырту» бүлеген мәҗбүри кертеп, коллектив шартнамәләр төзү | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 12 | Район оешмаларында һәм предприятиеләрендә, учреждениеләрендә биналарны һәм эш урыннарын янгын сүндерү җайланмалары һәм аптечкалар белән тәэмин итү | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 2018 – 2020 | Бюджеттан тыш акчалар |
| 13 | Биналарга техник карау үткәрү, биналарның техник торышы һәм куркынычсыз эксплуатациясе өчен җаваплы кеше билгеләү, тиешле журналларның булдыру | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре, учреждениеләре, кече һәм урта бизнес субъектлары | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 14 | Хезмәтне саклау буенча Координацион совет эшен оештыру, утырышлар уздыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 15 | Хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы һәм җитештерү травматизмын анализлау турында квартал саен доклад әзерләү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 16 | Производствода бәхетсезлек очракларына (төркемле, үлем белән тәмамланган һәм авыр нәтиҗәләргә китергән) юл куйган предприятие җитәкчеләрен хезмәтне саклау буенча Координацион совет утырышына чакыру) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 17 | Кукмара муниципаль районы оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре катнашында семинарлар, киңәшмәләр, «Түгәрәк өстәлләр», «Хезмәтне саклау көннәре» үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18 | Кукмара муниципаль районында хезмәтне саклау айлыклары оештыру һәм үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 19 | Ел саен үткәрелә торган «Бөтендөнья хезмәтне саклау көне»н уздыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 20 | Массакүләм мәгълүмат чараларында, Кукмара муниципаль районы сайтында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (оператив мәгълүматны бастыру һ. б.) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 21 | Хезмәтне саклау темасына социаль реклама эшләү һәм урнаштыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 2018 – 2020 | Җирле бюджет |
| 22 | Кукмара муниципаль районы халкына оешмаларда хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау турында мәгълүмат җиткерү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 23 | Производствода бәхетсезлек очракларын тикшерүдә катнашу, тикшерү материалларын карау һәм әлеге бәхетсезлек очракларына китергән сәбәпләрне бетерү буенча чаралар күрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районы профсоюзларының Координацион советы | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 24 | Җитештерү травматизмы, авариялелек һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе югары булган яки үсүгә юл куйган оешмаларда күзәтчелек һәм контроль органнары тарафыннан үткәрелә торган тикшерүләрдә катнашу | Хезмәтне саклау буенча Координация советы, Кукмара муниципаль районы профсоюзларының координацион советы | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |
| 25 | Район оешмаларында хезмәт шартларын махсус бәяләүне (хезмәт шартлары буенча эш урыннарын | Хезмәтне саклау буенча Координация советы | чаралар оештыру характерында | | | 2018 – 2020 | финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | аттестацияләүне) үткәрүне активлаштыруга ярдәм күрсәтү | | | | |
| 26 | Кукмара муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре арасында хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча эшләрне иң яхшы оештыру буенча район смотр-конкурсы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Хезмәтне саклау буенча Координацион совет | чаралар оештыру характерында | 2018 – 2020 | финанслаусыз |

**2 нче кушымта**

**2018 елга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча Координация советының эш планы**

| № | Үткәрү датасы | Чаралар исеме | Үткәрү урыны | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кварталга бер тапкыр | Координация советы утырышын уздыру | Башкарма комитет | Координация советы |
| 2. | Ярты елга бер тапкыр | Төзелеш оешмаларында һөнәри авырулар торышы, производство травмаларының торышы турында | Төзелеш оешмалары | Координация советы |
| 3. | 2 квартал | Төзелеш оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча айлыкка йомгак ясау | Башкарма комитет | Координация советы |
| 4. | 2 квартал | Төзелеш оешмаларында хезмәтне саклау буенча инженерларның эш тәҗрибәсе турында | Башкарма комитет | Координация советы |
| 5. | 28.04.2018 ел | Район оешмаларында Бөтендөнья хезмәтне саклау көнен үткәрү. | Район предприятиеләре һәм оешмалары | Координация советы, район предприятиеләре һәм оешмалары |
| 6. | ел дәвамында | Төзелеш оешмаларында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын уртак тикшерүләр үткәрү | Төзелеш мәйданчыклары | Координация советы |
| 7. | 3 квартал | Хезмәткәрләрне шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү | Төзелеш оешмалары | Координация советы |
| 8. | ел дәвамында | Хезмәтне саклау буенча җитәкчеләр һәм белгечләрнең һәм хезмәтне саклау буенча вәкаләтле предприятиеләрнең хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, семинарларда, түгәрәк өстәлләрдә катнашуын оештыру | Башкарма комитет | Координация советы |
| 9. | 4 квартал | 2018 елда хезмәтне саклау буенча Координация советының эш планын һәм 2019 елга эш планын үтәү йомгаклары | Башкарма комитет | Координация советы |
| 10. | Хәбәрләр керү карап | Производствода бәхетсезлек очракларын тикшерүдә катнашу | Район предприятиеләре һәм оешмалары | Координация советы |